**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№12415**
**22.12.2023**

2024 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү алымын сайлау турында карар, торак урынны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урын милекчеләре өчен торак урынны карап тотуга түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясының 4 өлеше нигезендә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Күпфатирлы йорт белән идарә итү алымын сайлау турында карар, торак урынны карап тотуга түләү күләме билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урын милекчеләре өчен торак урынны карап тотуга түләү күләмен билгеләү буенча, шулай ук шундый түләү күләмен үзгәртүнең чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү буенча методик рекомендацияләрне раслау турында» 2018 елның 6 апрелендәге 213/пр номерлы Приказының 3.6, 4.1 пунктларына, шәһәр Уставының 41 статьясындагы 9 өлешнең 4 пунктына туры китереп,

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. 2024 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар, торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урын милекчеләре өчен торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын 7,2 процент күләмендә билгеләргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов